**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Программа охр. тр.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 ел, 11 гыйнвар** Болгар ш. **№ 13**

**«Спас муниципаль районының 2019-2021 елларга Хезмәт шартларын һәм хезмәт саклауны яхшырту программасы»н раслау турында**

Хезмәтне саклау өлкәсендә Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының закон һәм норматив актларын гамәлгә ашыру, шартларны һәм хезмәтне саклауны яхшырту, хезмәткәрләргә сәламәтлек һәм хезмәтнең куркынычсыз шартларын гарантияләүче җитештерү чараларына, технологияләргә һәм хезмәтне оештыруга таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү максатыннан, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Спас муниципаль районының 2019-2021 елларга Хезмәт шартларын һәм хезмәт саклауны яхшырту программасын расларга.
2. Мөлкәтнең барлык формаларындагы предприятиеләр, оешмалар җитәкчеләренә 2019-2021 елларга хезмәт шартларын һәм хезмәт саклауны яхшырту буенча чаралар планын кабул итүне киңәш итәргә.
3. Бу Программаның үтәлешен контрольдә тотуны Спас муниципаль районының Хезмәтне саклау буенча координация советына йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1637005464

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 гыйнварындагы 13 номерлы карары белән расланды

# СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ 2019-2021 ЕЛЛАРГА ХЕЗМӘТ ШАРТЛАРЫН ҺӘМ ХЕЗМӘТ САКЛАУНЫ ЯХШЫРТУ ПРОГРАММАСЫ

«2019-2021 елларга Спас муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәт саклауны яхшырту»
**муниципаль программасының паспорты**

| | |
|---|---|
| Муниципаль максатчан программаның атамасы | «2019-2021 елларга Спас муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәт саклауны яхшырту» муниципаль программасы (алга таба Программа дип атала) |
| Программаны төзү өчен нигезләр | Россия Федерациясе Хезмәт кодексы;<br>Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләре;<br>«Эш урынындагы бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү турында» 1998 елның 24 июлендәге 125-ФЗ номерлы федераль закон;<br>«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль закон;<br>Тормыш дәрәҗәсен яхшырту һәм керемнәрне легальләштерү буенча республика ведомствоара комиссиясенең 2011 елның 20 декабрендәге 119 номерлы карары |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны | Спас муниципаль районының Хезмәтне саклау буенча |

| | |
|---|---|
| төзүчеләр | координация советы;<br>Спас муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге. |
| Программаның максаты | 1. Муниципаль район территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең эш урынында травма алуын һәм һөнәри авыруларын киметү максатыннан, хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту.<br>2. Хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру.<br>3. Эшләүчеләрне хезмәтне саклау өлкәсендә хокукый яклауның нәтиҗәлелеген арттыру.<br>4. Хезмәткәрләрне һөнәри хәвеф-хәтәрдән социаль яклау гарантияләре дәрәҗәсен күтәрү.<br>5. Оешмалар җитәкчеләрен, белгечләрен, эшкуарларны хезмәтне саклау буенча укыту һәм хезмәтне саклау таләпләрен белүләрен тикшерү системасын камилләштерү.<br>6. Эшләүче халыкка дәвалау-профилактика хезмәте күрсәтүне камилләштерү.<br>7. Хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча федераль һәм республика законнары таләпләрен Спас муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыру. |
| Программаның төп бурычлары | 1. Хезмәтне саклауны дәүләт идарә итүе системасын үстерү.<br>2. Заманча укыту технологияләре нигезендә, хезмәткәрләрне хезмәтне саклау буенча өзлексез әзерләп тору.<br>3. Мәгълүмат белән тәэмин итү һәм хезмәтне саклауны пропагандалау. |
| Программаның максатчан индикаторлары | 1. Эш урынындагы бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә һәлак булганнар саны (кеше).<br>2. Эш урынындагы бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә 1 эш көненә һәм артыгракка эшкә яраклылыкларын югалтып зыян күргәннәр саны (кеше).<br>3. Эш урынындагы имгәнүләргә һәм травмаларга бәйле рәвештә зыян күргән 1 кешегә исәпләгәндә, эшкә яраксызлык кеше/көннәре саны;<br>4. Санитария-гигена нормаларына җавап бирми торган шартларда эшләүче хезмәткәрләр өлеше (процент).<br>5. Ачыкланган һөнәри авыруларның 1000 хезмәткәргә туры килә торган өлеше. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2019-2021 еллар. |
| Программаның | Хезмәткәрләргә һәм эш бирүчеләргә хезмәтне саклау |

| | |
|---|---|
| төп чаралары исемлеге | мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү, консультацияләр үткәрү һәм хокукый ярдәм күрсәтү, хезмәтне саклау чараларын пропагандалау һәм популярлаштыру;<br>заманча укыту технологияләре нигезендә, хезмәткәрләрне хезмәтне саклау буенча өзлексез укытып тору системасын камилләштерү;<br>социаль һәм хезмәт мөнәсәбәтләре субъектларының хезмәтне саклау өлкәсендә социаль партнерлыгын камилләштерү. |
| Программаның төп чараларын башкаручылар | Спас муниципаль районы хакимияте;<br>Спас муниципаль районының эш бирүчеләре;<br>һөнәр берлекләре органнары, Спас муниципаль районының Хезмәтне саклау буенча координация советы. |
| Елларга бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Спас муниципаль районының мөлкәтнең барлык формаларындагы предприятиеләренең, оешмаларының үз акчалары һәм Социаль иминиятләштерү фонды акчасы тәшкил итә (мең сум), шул исәптән елларга бүлеп:<br>2019 ел – 15500 мең;<br>2020 ел – 15800 мең;<br>2021 ел – 16000 мең. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре | 1. 2019-2021 елларга билгеләнгән индикаторларның чик кыйммәтләренә ирешү:<br>эш урынында зыян күргәннәр санын, 1000 эшләүчегә исәпләгәндә, 0,65тән 0,6 кешегә кадәр шул исәптән үлем белән тәмамланганнар – 0 (кеше);<br>эш урынындагы имгәнүләргә һәм травмаларга бәйле рәвештә зыян күргән 1 кешегә исәпләгәндә, эшкә яраксызлык кеше/көннәре санын 30,0 га кадәр;<br>санитария-гигиена нормаларына җавап бирми торган шартларда эшләүче хезмәткәрләр өлешен 18,0 процентка кадәр киметү.<br>2. Социаль нәтиҗәлелек:<br>хезмәтнең уңайсыз шартларында мәшгуль хезмәткәрләр санын киметү;<br>эш урынында травма алу һәм һөнәри авырулар дәрәҗәсен киметү;<br>хезмәткәрләрне җитештерүдәге зыянлы һәм куркыныч факторлар тәэсиреннән яклау дәрәҗәсен арттыру;<br>хезмәткәрләрне хезмәтнең куркынычсыз шартлары белән тәэмин итүнең Конституциядә язылган хокукларын гамәлгә ашыру.<br>3. Икътисадый нәтиҗәлелек:<br>эш урынындагы бәхетсезлек очракларыннан, эшкә бәйле рәвештә барлыкка килгән авырулардан, һөнәри авырулардан зыян күргән хезмәткәрләрнең сәламәтлеген |

| | |
|---|---|
| | торгызуга матди чыгымнарны киметү;<br>эш урынындагы бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә хезмәткәрләргә китерелгән зыянны каплау чыгымнарын киметү. |
| Программа үтәлешенә контрольне оештыру | Программа үтәлешенә контроль түбәндәгеләр тарафыннан башкарыла:<br>Спас муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Спас муниципаль районының Хезмәтне саклау буенча координация советы. |

## 1. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программ ысуллар белән хәл итү зарурлыгын нигезләү

Хәзерге заман икътисадый шартларында эш урыннарында хезмәтнең сәламәт һәм куркынычсыз шартларын тудыру җәмгыятьнең социаль-икътисадый иминлегенә шактый зур йогынты ясый.

Программа хезмәтне саклауны дәүләт идарә итүенең яңа икътисад һәм хезмәт мөнәсәбәтләренә туры килүче системасын тагын да камилләштерүгә, хезмәт эшчәнлеге процессында хезмәткәрләрнең гомерен һәм сәламәтлеген саклау таләпләренә җавап бирүче хезмәт шартларын, дәүләт гарантияләрен һәм эшләүчеләрне хокукый яклауны, хезмәтне саклауны тәэмин итүгә, эш урынында травма алуны һәм һөнәри авыруларны алдан кисәтүгә һәм булдырмый калуга юнәлдерелгән.

Хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау өлкәсендәге вазгыять Спас муниципаль районында тулаем Татарстан Республикасындагыга караганда яхшырак. Соңгы елларда Спас районында эш урынында травма алуның (үлем белән тәмамланганнарының да, эш урынында авыр җәрәхәт алган хезмәткәрләрнең дә) гомуми дәрәҗәсе кимүнең уңай тенденциясе урнашты.

Хезмәткәрләрнең хезмәт иминлеге, аларның гомере һәм сәламәтлеге хезмәтне саклауга бүлеп бирелүче суммага турыдан-туры бәйле. Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 226 нчы статьясына тәңгәл рәвештә, хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту чараларын финанслау эш бирүченең бурычы булып тора.

Эш урыннарында һөнәри хәвеф-хәтәрләрне киметү максатыннан, хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәткәрләрне максатчан укыту һәм һөнәри яктан әзерләү зур әһәмияткә ия. Бу мәсьәләгә районда аерым игътибар бирелә, чөнки эш бирүчеләрнең хезмәтне саклау өлкәсендәге кагыйдәләрне иң зур бозулары хезмәткәрләрне хезмәтне саклау буенча укыту һәм инструктаж уздыру мәсьәләләренә бәйле.

Эш урынында травма алу сәбәпләрен анализлап, шуны әйтергә кирәк: соңгы еллар дәвамында аларның характеры үзгәрмәгән. Төп сәбәпләр булып түбәндәгеләр тора:

- хезмәт дисциплинасын бозу;
- хезмәтнең куркынычсыз шартларына өйрәтүдәге кимчелекләр.

Спас муниципаль районында Хезмәтне саклау буенча координация

советы оештырылды һәм эшләп килә. Хезмәтне саклау буенча координация советы утырышларында, эшләр башкарганда, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы таләпләрен үтәү, хезмәтне саклау буенча белгечләрне укыту һәм квалификацияләрен күтәрү, төзелеш оешмаларында эшләүчеләргә даими инструктажлар уздыру, медицина тикшерүләре үткәрү мәсьәләләре, Спас районында балаларны сәламәтләндерү һәм ялларын оештыру, җәйге ял вакытында яшүсмерләрнең эш урынында травма алуын булдырмый калу турында, эш урынында травма алуны киметү, эш урынындагы бәхетсезлек очракларын һәм һөнәри авыруларны булдырмый калу турында, төзелеш объектларында хезмәтнең куркынычсыз шартларын тәэмин итү һәм террорчылыкка каршы көрәш режимын көчәйтү, хезмәт шартларын махсус бәяләү турында, Спас муниципаль районы оешмаларында хезмәтне саклау хакындагы законның үтәлеше турында мәсьәләләр карала.

## 2. Программаның максаты һәм бурычлары

Муниципаль программаның максаты булып түбәндәгеләр тора:

- Спас муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең эш урынында травма алуын һәм һөнәри авыруларын киметү максатыннан, шартларны һәм хезмәтне саклауны яхшырту.

Куелган максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычларны хәл итү зарур:

- хезмәтне саклау өлкәсендә норматив хокукый базаны камилләштерү;
- хезмәткәрләрне хезмәтне саклау буенча укытуны оештыру;
- мәгълүмат белән тәэмин итү һәм хезмәтне саклауны пропагандалау;
- эшләүче халыкка дәвалау-профилактика хезмәте күрсәтүне камилләштерү;
- һөнәри авырулар белән чирләү һәм эш урынында травма алу дәрәҗәсен киметү;
- хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны мониторинглау;
- эш урыннарындагы шартларга һәм хезмәтне саклауга махсус бәяләү үткәрү һәм аларны хезмәтне саклауның норматив таләпләре белән тәңгәлләштерү.

## 3. Программаны гамәлгә ашыруга идарә итү һәм аны үтәү барышын контрольдә тоту

Программаны гамәлгә ашыруга идарә итүне муниципаль заказчы – Программаның координаторы – Спас муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

Муниципаль заказчы – Программаның координаторы:

- максатчан индикаторларны әзерләү һәм төгәлләштерү буенча эшчәнлекне, Программа чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнарны, Программаны гамәлгә ашыру механизмын һәм аны үтәүчеләр составын координацияли;
- Программаны гамәлгә ашыру буенча эшләрнең барышы һәм финанс

чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында ел саен, билгеләнгән тәртиптә, мәгълүмат җибәрә.

Программаны гамәлгә ашыру, гамәлдәге законнарга туры китереп, муниципаль ихтыяҗлар өчен продукция (хезмәт күрсәтүләр) сатып алуга һәм аларны китереп бирүгә муниципаль контрактлар (килешүләр) нигезендә башкарыла.

## 4. Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре

Программа оештыру, методик, санитария-гигиена, укыту-пропагандалау, җитештерү буенча күреләә торган һәм куелган максатларга ирешүне тәэмин итүче башка чараларның бердәм комплексы буларак төзелде һәм гамәлгә ашырыла.

Программаны төзегәндә, аны гамәлгә ашыру чыгымнарын оптимальләштерүгә, бер үк вакытта Программа чараларын үтәгәндә социаль нәтиҗәлелеккә ирешүгә юнәлеш алуга аерым игътибар бирелде.

Нәтиҗәләргә ирешүнең нәтиҗәлелеге яшәеш сыйфаты индикаторларының чик кыйммәтләренә ирешү белән билгеләнә:

- җирле үзидарә органнары җитәкчеләрен һәм белгечләрен хезмәтне саклау буенча укытуның 20гә кадәр кешене; 1000 эшләүчегә 18,25кә кадәр кешене колачлавы;
- эш урынында травма алу дәрәҗәсен 15 процентка киметү;
- хезмәтне саклау чараларына чыгымнарны 1 эшләүчегә исәпләгәндә, 12000 сумга кадәр арттыру.

Программаның социаль нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр белән бәяләнә:

- эш урынында травма алу һәм һөнәри авырулар белән чирләү дәрәҗәсен киметү;
- хезмәткәрләрне җитештерүдәге зыянлы һәм куркыныч факторлар тәэсиреннән яклау дәрәҗәсен арттыру;
- хезмәтнең уңайсыз шартларында мәшгуль хезмәткәрләр санын киметү;
- эш бирүчеләрнең күбрәк игътибарын хезмәткәрләрнең хезмәтен саклау проблемаларына җәлеп итү;
- шәһәр һәм район оешмаларында хезмәтне саклау буенча белгечләр санын арттыру.

Икътисадый нәтиҗәлелек ул:

- эш урынындагы бәхетсезлек очракларыннан, эшкә бәйле рәвештә барлыкка килгән авырулардан, һөнәри авырулардан зыян күргән хезмәткәрләрнең сәламәтлеген торгызуга матди чыгымнарны киметү;
- эш урынындагы бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә хезмәткәрләргә китерелгән зыянны каплау чыгымнарын киметү;
- хезмәтнең зыянлы һәм куркыныч шартларында, хезмәтнең авыр шартларында эшләгән өчен ташламалар һәм компенсацияләр бирүгә чыгымнарны киметү;

- эш вакытын исраф итүне киметү һәм керем күләмен арттыру хисабына хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү;

- хезмәт шартларын яхшырту хисабына кадрларның еш алышынуын киметү.

Хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча чаралар күрүче оешмалар икътисадый нәтиҗәлелекне шулай ук гамәлдәге законнар таләпләрен бозган өчен түләнә торган штрафлар кимү хисабына да ала.

Программаны үтәү халыкның үлү күрсәткечен (хезмәткә яраклы яшьтә аеруча) киметү өчен уңайлы шартлар тудыра.

Программаны үтәүнең экологик нәтиҗәлелеге – технологик процессларны камилләштерү, шулай ук искергән станокларны һәм җиһазларны контрольдә тоту һәм вакытында алмаштыру аркасында, әйләнә-тирә мохиткә зарарлы матдәләр чыгарылып ташлануның булмавы.

Программа чараларының исемлеге, аларны үтәү срокларын, финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын күрсәтеп, Программага 1 нче кушымтада бирелде.

Спас муниципаль районында
2019-2021 елларга Хезмәт шартларын
һәм хезмәтне саклауны яхшырту
муниципаль программасына
1 нче кушымта

## Программа чаралары исемлеге

| Т-п № | Чаралар атамасы | Үтәүчеләр | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|
| 1. | Җирле үзидарә органнары җитәкчеләрен һәм белгечләрен хезмәтне саклау буенча укытуны оештыру | Спас муниципаль районы Башкарма комитеты, район предприятиеләре һәм оешмалары | 2019-2021 еллар зарурлыкка карап |
| 2. | Хезмәтне саклау буенча аерым җитәкчеләрне һәм белгечләрне хезмәтне саклау буенча укытуны оештыру | Спас муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары, хезмәт, мәшгульлек, социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау, мәдәният учреждениеләре | 2019-2021 еллар зарурлыкка карап |
| 3. | Спас муниципаль районы | Спас муниципаль районы | ел саен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | оешмалары һәм учреждениеләренең хезмәтне саклау эшен иң яхшы оештыру буенча республика конкурсларында катнашуын тәэмин итү | Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Мәгариф бүлеге, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Мәдәният бүлеге, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Балалар һәм яшьләр эшләре бүлеге, Спас Үзәк район хастаханәсе | |
| 4. | Хезмәткәрләргә беренчел (эшкә урнашканда) һәм периодик медицина тикшеренүләрен үз вакытында үткәрүне тәэмин итү | Спас муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары, хезмәт, мәшгульлек, социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау, мәдәният учреждениеләре | 2019-2021 еллар |
| 5. | Хезмәтнең зыянлы шартларында мәшгуль хезмәткәрләр өчен предприятиеләрдә дәвалау-профилактика чаралары уздыру | Спас муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | 2019-2021 еллар |
| 6. | Хезмәтнең уңайсыз шартларында мәшгуль хезмәткәрләргә предприятиеләрдә ел саен диспансеризация уздыруны оештыру | Спас муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | 2019-2021 еллар |
| 7. | Мөлкәтнең барлык формаларындагы оешмаларда һәм предприятиеләрдә, учреждениеләрдә хезмәтне саклау буенча белгечләрнең нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итү | Спас муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | 2019-2021 еллар |
| 8. | Эш урыннарын хезмәт шартлары буенча | Спас муниципаль районы оешмалары һәм | 2019-2021 еллар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | аттестацияләү уздырып, соңыннан хезмәткәрләргә эш урыннарындагы шартлар һәм хезмәтне саклау турында, сәламәтлекләренә зыян килү куркынычы булу турында, аларга тиешле компенсацияләр һәм индивидуаль саклану чаралары турында мәгълүмат бирү | предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | |
| 9. | Район оешмаларында һәм предприятиеләрендә, учреждениеләрендә хезмәтне саклау буенча кабинетлар булдыру | Спас муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | 2019-2021 еллар |
| 10. | Район оешмаларында һәм предприятиеләрендә, учреждениеләрендә хезмәтне саклау буенча инженерны кирәкле җиһаз һәм техника җыелмасы булган аерым кабинет белән тәэмин итү | Спас муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | 2019-2021 еллар |
| 11. | «Хезмәтне саклау шартларын яхшырту» бүлеген кертеп, коллектив килешүләр төзү | Спас муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | 2019-2021 еллар |
| 12. | Район оешмаларында һәм предприятиеләрендәге, учреждениеләрендәге бүлмәләрне һәм эш урыннарын янгын сүндергечләр һәм аптечкалар белән тәэмин итү | Спас муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | 2019-2021 еллар |
| 13. | Биналарга техник күзәтү үткәрү, биналарның техник торышы һәм аларны куркынычсыз файдалану өчен җаваплы | Спас муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес | 2019-2021 еллар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | кеше билгеләү, тиешле журналлар башлау | субъектлары | |
| 14. | Хезмәтне саклау буенча координация советы эшчәнлеген оештыру, утырышлар уздыру | Спас муниципаль районы Башкарма комитеты | |
| 15. | Шартларның һәм хезмәтне саклауның торышы турында квартал саен доклад әзерләү һәм эш урынында травма алуга анализ ясау | Спас муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча координация советы | квартал саен |
| 16. | Хезмәтне саклау буенча координация советы утырышларына эш урынындагы бәхетсезлек очракларына (төркемләп, үлем белән тәмамланган һәм авыр нәтиҗәләргә китергән) юл куйган предприятиеләр җитәкчеләрен чакыру | Спас муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча координация советы | 2019-2021 еллар |
| 17. | Спас муниципаль районы оешмалары җитәкчеләре һәм белгечләре катнашында семинарлар, киңәшмәләр, «түгәрәк өстәл»ләр, «хезмәтне саклау көннәре» уздыру | Спас муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча координация советы | 2019-2021 еллар |
| 18. | Район күләмендә ел саен «Бөтендөнья хезмәтне саклау көне»н уздыру | Спас муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча координация советы | 2019-2021 еллар |
| 19. | Хезмәтне саклау темасына социаль реклама уйлап табу һәм урнаштыру | Спас муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча координация советы | 2019-2021 еллар |
| 20. | Эш урынындагы бәхетсезлек очракларын тикшерүдә катнашу, тикшерү материалларын карау һәм шул бәхетсезлек очракларын китереп чыгарган сәбәпләрне | Спас муниципаль районы Башкарма комитеты, Спас муниципаль районы һөнәр берлекләренең координация советы | 2019-2021 еллар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | бетерү буенча чаралар күрү | | |
| 21. | Эш урынында травма алучыларның артуына юл куйган яки травмалар, һәлакәтләр, һөнәри авырулар саны бик күп булган оешмаларда күзәтчелек һәм контроль органнары тарафыннан уздырылучы тикшерүләрдә катнашу | Хезмәтне саклау буенча координация советы, Спас муниципаль районы һөнәр берлекләренең координация советы | 2019-2021 еллар |
| 22. | Район оешмаларында хезмәт шартларын махсус бәяләү (эш урыннарын хезмәт шартлары буенча аттестацияләү) үткәрүне активлаштыруга булышлык итү | Хезмәтне саклау буенча координация советы | 2019-2021 еллар |
| 23. | Спас муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре арасында хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы буенча эшләрне иң яхшы оештыруга район смотр-конкурсын уздыру | Спас муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча координация советы | 2019-2021 еллар |